КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 10 июль г.Казань № 561

Татарстан Республикасында ирекле-
лекне (волонтерлыкны) үстерү буенча
ведомствоара совет оештыру турында

Татарстан Республикасында ирекчеләр (волонтерлар) хәрәкәтен үстерү һәм аңа булышлык күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында ирекчелекне (волонтерлыкны) үстерү буенча ведомствоара совет оештырырга.

2. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында ирекчелекне (волонтерлыкны) үстерү буенча ведомствоара совет турындагы нигезләмәне һәм аның составын расларга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 10 июль, 561 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасында
иреклелекне (волонтерлыкны) үстерү буенча ведомствоара совет турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасында иреклелекне (волонтерлыкны) үстерү буенча ведомствоара совет (алга таба – Ведомствоара совет) ирекләләр (волонтерлар) эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының үзара килешенгән гамәлләрен һәм аларның иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында оештырылган орган булып тора.

1.2. Ведомствоара совет үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм бу Нигезләмәгә таянып эш итә.

2. Ведомствоара советның төп бурычлары һәм функцияләре

2.1. Ведомствоара советның төп бурычлары һәм функцияләре:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының иҗтимагый оешмалар белән иреклелек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;

Татарстан Республикасында иреклелекнең (волонтерлыкның) өстенлекле юнәлешләренә ярдәм күрсәтү һәм ирекләләр (волонтерлар) эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр формалаштыру;

ирекләләр (волонтерлар) эшчәнлегенең төп юнәлешләренә (мәгариф, сәламәтлек саклау, гражданлык-патриотик тәрбия бирү, мәдәният, социаль ярдәм күрсәтү һәм халыкка социаль хезмәт күрсәтү, физик культура һәм спорт, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм алар салган зыяннарны бетерү, эчке эшләр органнарына булышлык күрсәтү, вакыйгаи, инклюзив, корпоратив иреклелек (волонтерлык), өлкән яшьтәге гражданнарның ирекләләр (волонтерлар) эшчәнлеге – «көмеш волонтерлык» өлкәсендә) методик ярдәм күрсәтү;

иреклелек (волонтерлык) буенча Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары проектларын тикшерү;

Татарстан Республикасында ирекләләр (волонтерлар) эшчәнлегенә комплекслы анализ ясауны гамәлгә ашыру һәм иреклелеккә (волонтерлыкка) ярдәм күрсәтү буенча тәҗрибәләрне гомумиләштерү.

## 3. Ведомствоара советның хокуклары

3.1. Ведомствоара совет үзенә йөкләнгән функцияләрне үтәү өчен түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасында иреклелекне (волонтерлыкны) үстерүнең өстенлекле юнәлешләре буенча тәкъдимнәр кертергә;

Татарстан Республикасында иреклелек (волонтерлык) эшчәнлегенең норматив хокукый базасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертергә;

Совет эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны республика башкарма хакимият органнарыннан һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарыннан билгеләнгән тәртиптә соратып алырга;

үз утырышларында Ведомствоара совет эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләрне карап тикшерергә һәм алар буенча карарлар кабул итәргә;

Совет утырышларында катнашу өчен республика башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары вәкилләрен чакырырга.

## 4. Ведомствоара совет составы һәм аның эшчәнлеген оештыру

4.1. Ведомствоара совет түбәндәге составта төзелә: Совет рәисе, Совет рәисе урынбасары, Совет секретаре һәм Советның башка әгъзалары.

4.2. Ведомствоара совет составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

4.3. Ведомствоара совет рәисе аның эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, Ведомствоара совет утырышларын үткәрә, Ведомствоара советның эш планын раслый, Ведомствоара совет эшчәнлеге кысаларында Ведомствоара совет әгъзалары арасында йөкләмәләрне бүлә, үзенә йөкләнгән бурычлар һәм функцияләр нигезендә Ведомствоара совет әгъзаларына тиешле йөкләмәләр бирә, Ведомствоара советның беркетмәләренә һәм башка документларына имза куя.

4.4. Ведомствоара совет рәисе булмаганда, аның вәкаләтләрен Ведомствоара совет рәисе кушуы буенча Ведомствоара совет рәисе урынбасары гамәлгә ашыра.

4.5. Ведомствоара совет секретаре:

Ведомствоара совет рәисе йөкләмәләрен башкара, Ведомствоара советның эш башкаруын оештыра, Ведомствоара совет эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр буенча хатлар язышуны алып бара;

Ведомствоара совет әгъзалары белән үзара хезмәттәшлек итеп, көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча Ведомствоара совет утырышына мәгълүмат-аналитика материалларын әзерләүне тәэмин итә;

Ведомствоара совет әгъзаларына Ведомствоара совет утырышының вакыты, урыны һәм көн тәртибе турында хәбәр итә;

Ведомствоара совет карарларының исәбен алып бара һәм аларның үтәлешен агымдагы тикшерүдә тота;

Ведомствоара совет рәисенә йә Совет утырышында рәислек итүче Ведомствоара совет рәисе урынбасарына доклад әзерли;

Ведомствоара совет карарларын үтәүчеләргә һәм кызыксынучы оешмаларга җибәрә;

Ведомствоара совет утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә һәм аларга имза куя;

Ведомствоара совет эшчәнлеге материалларын, шул исәптән Ведомствоара совет беркетмәләренең төп нөсхәләрен саклауны оештыра;

Ведомствоара совет эшен тиешенчә оештыру өчен кирәкле башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

4.6. Ведомствоара совет утырышлары кирәк булуга карап, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Ведомствоара совет утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы дип санала. Ведомствоара совет утырышларына материаллар Ведомствоара совет секретаре тарафыннан, Ведомствоара совет утырышы үткәрелә торган көнгә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча, Ведомствоара совет әгъзаларына җибәрелергә тиеш.

4.7. Ведомствоара совет әгъзасы Ведомствоара совет утырышларында шәхсән үзе катнашырга тиеш. Утырышта катнашу мөмкинлеге булмаган очракта, Ведомствоара совет әгъзасы бу турыда Ведомствоара совет рәисенә, булмауның сәбәбен күрсәтеп, хәбәр итәргә тиеш.

4.8. Ведомствоара совет утырышларында тикшерелә торган мәсьәләләр Ведомствоара совет карары белән рәсмиләштерелә, ул утырышта катнашучы затларның гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә; мәсьәләләр утырышлар беркетмәләренә теркәлә, аларга Ведомствоара совет рәисе имза куя. Тавышлар саны тигез булганда, Ведомствоара совет рәисе йә Ведомствоара совет утырышында рәислек итүче Ведомствоара совет рәисе урынбасары тавышы хәлиткеч була.

4.9. Ведомствоара совет утырышы йомгаклары буенча беркетмәләр утырыш үткәрелгән көннән 10 эш көне эчендә рәсмиләштерелә һәм, Ведомствоара совет рәисе имзасын куйганнан соң, өч көн эчендә Ведомствоара советның барлык әгъзаларына, кызыксынучы республика башкарма хакимият органнарына һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына җибәрелә.

4.10. Ведомствоара советның үз компетенциясе нигезендә кабул ителә торган карарлары тәкъдим итү характерына ия.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 10 июль, 561 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасында
иреклелекне (волонтерлыкны) үстерү буенча ведомствоара совет
составы

| | |
|---|---|
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Ведомствоара совет рәисе |
| Фәттахов Дамир Илдус улы | Татарстан Республикасының яшьләр эшләре министры, Ведомствоара совет рәисе урынбасары |
| Мөбәрәкшин Айрат Илдус улы | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасының волонтерлар белән эшләү департаменты җитәкчесе, Ведомствоара совет секретаре (килешү буенча) |

Ведомствоара совет әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Абдреева Юлия Ивановна | Татарстан Республикасының хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары |
| Әсәдуллина Алсу Мөниб кызы | Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры урынбасары |
| Биканова Эльвира Рәис кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары ярдәмчесе |
| Галимов Айнур Газинур улы | Татарстан Республикасы юстиция министрының беренче урынбасары |
| Зарипов Раушан Булат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә караган физик культура һәм спортны үстерү бүлекчәсе мөдире |
| Захматова Анна Андреевна | Татарстан Республикасының яшьләр эшләре министры урынбасары |

| | |
|---|---|
| Идрисов Азат Альберт улы | «Җиңү волонтерлары» бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан төбәк бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| Исмәгыйлев Марат Шамил улы | «Добрая Казань» коммерциягә карамаган автоном оешмасы директоры (килешү буенча) |
| Карпов Александр Андреевич | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Макарова Елена Владимировна | «Төбәк иҗтимагый коткару отряды» эзләү-коткару отряды җитәкчесе (килешү буенча) |
| Макарова Анна Вячеславовна | «Волонтерлар-табиблар» бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан төбәк бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| Миргалимов Илдар Флүс улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары |
| Мотыйгуллина Гөлфия Рифат кызы | «Мин – ирекле ярдәмче» социаль һәм иҗади ярдәм күрсәтү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы директоры (килешү буенча) |
| Раззакова Руфинә Равил кызы | «Россия мәктәп укучылары хәрәкәте» Татарстан төбәк бүлегенең төбәк координаторы (килешү буенча) |
| Сәетова Лиана Марсель кызы | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары |
| Сафин Тимур Фадбир улы | «Безнең эш» Татарстан Республикасы граждан башлангычларына ярдәм күрсәтүнең төбәк иҗтимагый хәрәкәте рәисе (килешү буенча) |
| Синеглазова Анна Григорьевна | «Республика яшьләр, инновация һәм профилактика программалары үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Суржко Николай Владимирович | Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министры вазыйфаларын вакытлыча башкаручы |
| Тарнавский Егор Александрович | Татарстан Республикасының экология һәм табигый байлыклар министры урынбасары |

| | |
|---|---|
| Фатыйхов Илдар Разин улы | Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау министры урынбасары |
| Фомин Анатолий Алексеевич | Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Шакирова Гүзәл Рәис кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы. |